МИНИСТЕРСТВО
ПО ДЕЛАМ МОЛОДЕЖИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**30.01.2019** **№21**

Казан шәһәре

Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгының Норматив хокук актлары һәм норматив хокук актлары проектларына карата ришвәтчелеккә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында

2009 елның 17нче июлендәге 172нче номерлы ФК «Норматив хокук актлары һәм норматив хокук актлары проектларына карата Ришвәтчелеккә каршы экспертиза уздыру» дип исемләнгән Федераль канун нигезендә, 2010 елның 26нчы февралендәге 96нчы номерлы «Норматив хокук актлары һәм норматив хокук актлары проектларына карата Ришвәтчелеккә каршы экспертиза уздыру» дип исемләнгән Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, 24.12.2009 елдагы 883нче номерлы «Аерым норматив хокук актлары һәм норматив хокук актлары проектларына карата ришвәтчелеккә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасының Министрлар кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» дип исемләнгән Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары нигезендә б о е р ы к бирәм:

1. Беркетелгән Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгының Норматив хокук актлары һәм норматив хокук актлары проектларына карата ришвәтчелеккә каршы экспертиза уздыру тәртибен расларга.

2. Дәүләт хезмәте, кадрлар һәм юридик хезмәт секторына, дәүләт теркәве өчен, әлеге Боерыкны Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына юлларга.

3. Эш башкару һәм тикшерү секторына, Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгында теркәлгәннән соң, әлеге Боерыкны Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгының барлык структур бүлекчәләренә җиткерергә.

4. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

**Министр** **Д.И.Фаттахов**

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре
министрлыгы боерыгы нигезендә
расланды
30.01.2019 № 21

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының норматив хокук актларына һәм норматик хокук актлары проектларына коррупциягә каршы экспретиза уздыру
ТӘРТИБЕ

I. Гомуми нигезләр

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгында (моннан соң – Министрлык) норматив хокук актларына һәм норматив хокук актлар проектларына, шулай ук Министрлык тарафыннан эшләнгән Татарстан Республикасы норматив хокук актларына (моннан соң – актлар, актлар проектлары) коррупциягә каршы экспретиза уздыру һәм коррупциягә каршы экспретиза нәтиҗәләрен исәпкә алып бару процедурасы тәртибен билгели.

1.2. Коррупциягә каршы экспертиза 2009 елның 17нче июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль канун, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Норматив хокук актларына һәм норматив хокук актларының проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру турында» 2010 елның 26нчы февралендәге 96нчы номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым норматив хокук актларга һәм норматив хокук актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 24нче декабрендәге 883нче номерлы карары, 2017 елның 29нче июнендәге УП-575 номерлы “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокук актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза белән

тәэмин итүне һәм аларны әзерләгәндә, җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуны өстәмә гарантияләү турында” дип исемләнгән Татарстан Республикасы Президенты Указы, шулай ук әлеге Тәртип нигезендә башкарыла.

1.3. Коррупциягә каршы экспертизаның максаты – норматив хокук актларында һәм норматив хокук актларның проектларында коррупциячел факторларны ачыклау һәм алга таба бетерү.

1.4. Коррупциягә каршы экспертиза гамәлдән чыгарылган яки үз көчен югалткан номартив хокук акталарына карата уздырылмый.

## II. Коррупциягә каршы экспертиза уздыру

2.1. Норматив хокук актларына һәм норматив хокук актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза Министрлыктагы вазифаи зат (моннан соң – вазифаи зат) тарафыннан башкарыла. Күрсәтелгән вазифаи зат Министрлыкта коррупциягә каршы экспертизага алынган норматив хокук актларына һәм норматив хокук актлар проектлары исәбен терки торган Кенәгәне (моннан соң – Кенәгә) алып бару өчен дә җаваплы (Әлеге Тәртипкә беркетелгән 1нче номерлы кушымта).

Җаваплы вазифаи зат Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министры (моннан соң – министр) тарафыннан билгеләнә.

2.2. Норматив хокук актлары һәм норматив хокук актлары проектлары структур бүлекчә җитәкчелеге тарафыннан коррупциягә каршы экспертизага юллана. Әлеге бүлекчә актлар проектларын эшләү өчен җаваплы, экспертизага үз ихтыярлары белән җибәрәләр.

2.3. Коррупциягә каршы экспертиза, норматив хокук актны һәм норматив хокук актлары проектын Кенәгәдә теркәгән көннән соң, ун көнлек срокта үткәрелә

2.4. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча, әлеге Тәртипкә беркетелгән 2нче номерлы кушымтада күрсәтелгән формада нәтиҗә ясала. Анда түбәндәге мәгълүмат тупланган булырга тиеш:

Экспертизага тәкъдим ителгән акт реквизитлары (акт проекты исеме);

актта коррупциоген факторлар булу яки булмау турында мәгълүмат;

актның (акт проектының) коррупциоген факторлар булган конкрет нигезләмәсе положения акта (проекта акта) (булган очракта);

коррупциоген факторлардан котылу өчен, акт (акт проектын) үзгәртү яки аерым бер шартларны алып ату буенча тәкъдимнәр (коррупциоген факторлар табылган очракта);

2.5. Вазифаи зат тарафыннан әзерләнгән һәм имзаланган актларга (акт проектларына) ясалган коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре төзелгән көнне әлеге актны (актлар проектын) җибәргән структур бүлекчәгә кире юллана.

2.6. Министрлыкның акт (актлар проектларын) әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе, коррупциягә каршы экспертиза вакытында ачыкланган коррупциоген факторлар күрсәтелгән нәтиҗәне алган вакытта, министр белән килешү нигезендә өч көнлек срок дәвамында, төзәтмәләрне исәпкә ала һәм төзәтмәләр кертелгән актны (актлар проектын), кабаттан карап чыгу өчен, вазифаи затка юллый.

Экспертизага җибәрелгән норматив хокук актлары проектында коррупциоген факторлар булмаса, эшләүче, коррупциоген факторлар юклыгы турындагы бәяләмәне алгач, норматив хокук акты проектын кызыксынган структур бүлекчәләрнең җитәкчеләренең имзалары белән, имза салу өчен, рәискә җибәрә.

## III. Норматив хокук актыларга һәм норматив хокук актыларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү тәртибе

3.1. Министрлыкның рәсми басылып чыккан һәм “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендәге Министрлыкның рәсми сайтында (алга таба – рәсми сайт) урнаштырылган Министрлык норматив хокук актылары, Министрлык тарафыннан эшләнә торган Татарстан Республикасы норматив хокук актыларның проектлары, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздырыр өчен, Татарстан Республикасы хакимияте органнарының норматив-хокук актлары һәм норматив-хокук актлар проектларын урнаштыру, җәмгыятькә таныту өчен юнәлдерелгән (http://tatarstan.ru/regulation) (моннан соң – бердәм региональ интернет-портал) актлар коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектлары була.

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларны яки конфиденциаль характердагы мәгълүматларны үз эченә алган

норматив хокук актыларга, норматив хокук актыларның проектларына карата үткәрелми.

3.2 Министрлык тарафыннан әзерләнгән, Россия Федерациясе Федераль Җыенының Дәүләт Думасына Татарстан Республикасының Дәүләт Советы канун чыгару инициативысы, Татарстан Республикасы кануннар проекты, Татарстан Республикасы Президенты Указлар проекты, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты боерыклар проекты рәвешендә тәкъдим ителә торган федераль кануннар, норматив хокук актылар һәм норматив хокук актылар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен, Министрлык аларны үзенең рәсми сайтына һәм “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәренә һәм бердәм региональ интернет-порталга бер көн эчендә урнаштыра.

3.3. Норматив хокук актының проектына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен эшләүче аны вазифаи затка рәис боерыгы белән билгеләнгән норматив хокук актыларның проектларын урнаштыру өчен җаваплы затка (алга таба – җаваплы зат) аларны вазифаи затка карап тикшерү өчен җибәрелгән көнгә туры килүче эш көне дәвамында җибәрә, проектны сайтта һәм бердәм интернет-порталда, экспертиза нәтиҗәләр җибәрү өчен, адресларны, шулай ук коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне кабул итә башлау һәм тәмамлау көнен күрсәтеп урнаштырып куя.

3.4. Норматив хокук актыларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү вакыты аларны рәсми сайтта урнаштырган көннән башлап кимендә биш эш көне дәвам итә.

3.5. Күрсәтелгән срокларда Министрлыкка җибәрелгән норматив хокук актыка, норматив хокук актының проектына карата коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре (моннан соң – йомгак-бәяләмә) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасында теркәлә һәм Министрлыкның структур бүлекчәсенә вазифаи җаваплы затка, актны карап чыгу өчен әзерләргә дип юллана.

3.6. Йомгак-бәяләмә киңәш бирү характерына ия һәм Дәүләт комитеты тарафыннан зарури тәртиптә карап тикшерелергә тиеш. Эшләүче килгән бәяләмәне карап тикшерә һәм аны алганнан соң 15 көнлек срокта коррупциягә каршы бәйсез

экспертиза үткәргән юридик яки физик затка дәлилләнгән җавап җибәрә, бәяләмәдә ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү ысулы турында тәкъдимнәр булмаган очраклардан тыш.

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәргән юридик яки физик затка, мотивлашкан йомгак-бәяләмә юллана (бәяләмәдә коррупциоген факторлар табылу яки ачыкланган коррупциоген факторларны юк итү турында тәкъдимнәр булмаган очраклардан тыш). Мотивлашкан бәяләмәдә коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре һәм (яки) норматив хокук актына яки норматив хокук актлар проектларында коррупциоген факторлар табылу белән килешмәү сәбәпләре күрсәтелә.

3.7. Түбәндәге өлкәләргә караган коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре каралмый:

Россия Федерациясенең Юстиция министрлыгы тарафыннан норматив хокук актларына һәм норматив хокук акталар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздырырга эксперт буларак аккредитация узмаган юридик һәм физик затлар әзерләгән бәяләмәләр;

Россия Федерациясенең Юстиция министрлыгы тарафыннан расланган формага туры килми торган бәяләмәләр;

Әлеге Тәртипнең 3.7 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән очракта, Министрлык кенәгәгә теркәлгән көннән соң 15 көннән дә соңармыйча, кире кайтару сәбәбен күрсәтеп, бәяләмәне кире кайтара.

3.8. Актлар проектына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру вакытында ачыкланган коррупциоген факторлар, актлар проектына төзәтмәләр кертү стадиясендә әлеге факторларны юк итәләр, төзәтәләр.

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздырудан соң актлар проектына төзәтмәләр кертелсә, актлар проектына кабаттан коррупциягә каршы бәйсез экспертиза ясалырга тиеш.

3.9. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәсендә ясалган бәяләмәдә күрсәтелгән хаталарны төзәткәннән соң, Министрлыкның актлар проектына әзерләү өчен җаваплы булган структур бүлекчәсе актлар проектын, коррупциягә каршы

бәйсез экспертиза бәяләмәсен беркетеп, кабаттан вазыйфаи җаваплы затка тапшыра. Актлар проектын кабаттан карау өч көн дәвамында башкарыла.

3.10. Әгәр актта коррупциоген факторлар табылса, Министрлыкның әлеге актны әзерләгән структур бүлекчәсе, Министрлыкта теркәлгәннән соң өч көнлек срок дәвамында актка үзгәрешләр кертү турында яки аны гамәлдән чыккан дип табу турында карар кабул итә.

3.11. Актны әзерләгән як, коррупциягә каршы экспертиза (шул исәптән, бәйсез экспертиза) бәяләмәсе (Россия Федерациясе Федераль Собрание Дәүләт Думасына Татарстан Республикасы Дәүләт советы канун чыгару инициативасы, Татарстан Республикасы кануннар проекты, Татарстан Республикасы Президенты указлары проекты, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты боерыклары проектлары рәвешендә бирелгән актларда коррупциоген фактлар табылса) белән килешмәсә, үзенең ризасызлыгын дәлилләп язган аңлатма кәгазе тапшыра ала.

## IV. Норматив хокук актлары проектлары җәмгыятькә чыгару, фикер алышу

4.1. Министрлык норматив хокук актлары проектларына карата җәмгыятьтә фикер алышуны оештыра.

4.2. Норматив хокук актлары проектларын, фикер алышу өчен, Татарстан Республикасының Рәсми порталында (http://tatarstan.ru/regulation), коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокук актларын урнаштыра торган бердәм региональ интернет-порталда (моннан соң – Мәгълүмати портал) урнаштырыла.

4.3. Фикер алышу өчен, Мәгълүмати ресурста гражданнарның хокукларына, мөмкинлекләренә һәм бурычларына кагылышлы норматив хокук актлары проектлары урнаштырыла.

4.4. Фикер алышу өчен, түбәндәге норматив хокук акталары урнаштырылмый:

дәүләт сере яки конфиденциаль эчтәлекле мәгълүмат булган номартив хокук актлары проектлары;

актларны үз көчен югалткан дип игълан итә торган норматив хокук акты проектлары;

Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Премьер-министры һәм аның урынбасарлары боерыгы нигезендә, фикер алышу срогыннан кимрәк срокта (Мәгълүмати ресурста урнаштырылганнан соң, биш эш көне дәвамында) әзерләнә торган номатив хокук акты проектлары;

Татарстан Республикасы бюджетының керемнәренә һәм чыгымнарына тәэсир итә торган норматив хокук актлары, Татарстан Республикасы бюджетын тулыландару белән бәйле норматив хокук акт проектлары;

оештыру мәсьәләләрен регламентлый торган, дәүләт хакимияте органнары эшчәнлеген, террорлык, шул исәптән финанс террорлык белән көрәшкә юнәлдерелгән чаралар вакытында дәүләт хакимияте органнарының үзара эшчәнлегенә кагылышлы норматив хокук актлар проектлары;

Татарстан Республикасының норматив хокук актлар проектларына канун таләпләре буенча үзгәрешләр кертүгә юнәлдерелгән норматив хокук актлары проектлары;

суд карарын, прокурор актларын, контроль һәм исәп органнары боерыкларын тормышка ашыру максатыннан әзерләнгән норматив хокук актлар проектлары;

дәүләт функцияләрен башкаруның административ регламентлар проекты һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентлар проекты;

статистик күзәтү формаларын раслау турында норматив хокук актлар проекты;

Татарстан Республикасының норматив хокук актларын гамәлдән чыгару турында норматив хокук актлар проектлары.

4.5. Норматив хокук актлары проектларын, фикер алышу өчен, Мәгълүмати порталга урнаштырганда, проектны әзерләгән структур бүлекчә, төзәтмәләр һәм тәкъдимнәр җибәреп булсын өчен, адрес (шул исәптән, электрон почта адресы), шулай ук фикер алышу башланган һәм тәмамланган көнне, срокларны күрсәтә.

4.6. Норматив хокук актлары проектлары турында фикер алышу сроклары, актларны әзерләгән оешма, бүлек тарафыннан билгеләнә һәм Мәгълүмати ресурста урнаштырылган көннән алып биш көннән дә азрак була алмый.

4.7. Фикер алышу нигезендә, норматив хокук актын әзерләгән оешма, бүлекчә тарафыннан норматив хокук актлары проектына үзгәрешләр һәм төзәтмәләр кертү

төрында карар кабул ителсә, төзәтмәләр кертелгән проект фикер алышу өчен, кабаттан Мәгълүмати ресурска урнаштырыла.

4.8. Норматив хокук актлары проектын Мәгълүмати ресурска урнаштыру Татарстан Респубдикасының Министрлар кабинеты боерыгы нигезендә башкарыла.

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза, фикер алышу тәмамланганнан соң 30 көнлек срокта, актны (актлар проектын) төзүче як коррупциягә каршы бәйсез экспертиза вакытында билгеләнгән коррупциоген фактлар, фикер алышу дәверендә яңгыраган тәкъдимнәр һәм аларны әлеге Тәртипкә беркетелгән 3нче номерлы кушымта нигезендә күрсәтелгән форма буенча карау турында ачык мәгълүмат урнаштыра.

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының норматив хокук актларына һәм норматив хокук актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә караган
1нче номерлы кушымта

Коррупциягә каршы экспертизага килгән норматив хокук актларын һәм норматив хокук актлары проектларын теркәү

КЕНӘГӘСЕ

| Актның (акт проектының) экспертизага килгән көне | Актны (акт проектын) юллаган структур бүлекчә | Актның (акт проектының) исеме | Коррупциоген фактларның булу/булмавы | Нәтиҗә ясалган көн | Акт һәм акт проектларына кагылышлы искәрмәләр (кабаттан экспертиза ясату турында мәгълүмат, икенчел экспертиза нәтиҗәләре буенча нәтиҗә ясалу көне) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |

Татарстан Ре
министрлыгын
норматив хо
корруциягә кар
караган
2нче номерлы к

Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәсе

______________________________________________________________________________

(норматив хокук акты реквизитлары яки норматив хокук акты проектының исеме)

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

2009 елның 17нче июлендәге 172нче номерлы ФК «Норматив хокук актлары һәм норма
карата Ришвәтчелеккә каршы экспертиза уздыру» дип исемләнгән Федераль канун, 24.
«Аерым норматив хокук актлары һәм норматив хокук актлары проектларына карата р
уздыру тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасының Министрлар кабинетының аеры
турында» дип исемләнгән Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары, 2010 е

номерлы «Норматив хокук актлары һәм норматив хокук актлары проектларына карата Р
уздыру» дип исемләнгән Россия Федерациясе Хөкүмәте карарының методикасы н
факторларны билгеләү, табылган очракта юк итү максатыннан, коррупциягә каршы эксперт

Проектта коррупциоген факторларның булу/булмавы:

______________________________________________________________________________

Актның коррупциоген факторлары булган конкрет нигезләмәләре:

______________________________________________________________________________

________________________________________

Коррупциоген факторларны юк итү өчен, кайбер нормаларга үзгәрешләр кертү яки алы

______________________________________________________________________________

_________________________________________________________________

Вазыйфаи җаваплы зат _______________ _______________

(имза) (Ф.И.О.)

Т
э
н
н
п
э
к
3

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза һәм (яки) фикер алыш

нәтиҗәләре буенча вакытлыча мәгълүмат

---

(норматив хокук акт төре, норматив хокук акты проектының ис

| Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза | | | |
|---|---|---|---|
| № п/п | Эксперт (ФИО (соңгысы – булган очракта гына)/аккредитацияне раслый торган реквизитлар) | Коррупциоген факторларны билгеләү | Актны әзерләгән якның шәрехләмәсе |
| | | | |
| | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| Фикер алышу | | | |
| № п/п | Фикер алышуда катнашкан зат (Ф.И.О. (соңгысы – булган очракта гына)/ электрон почта адресы) | Фикер алышуда катнашучы затның фикере | Актны әзерләгән якның шәрехләмәсе |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

| | |
|---|---|
| Яңгыраган тәкъдимнәрнең гомуми саны | |
| Кабул ителгән, исәпкә алынган тәкъдимнәрнең гомуми саны | |
| Өлешчә исәпкә алынган тәкъдимнәрнең гомуми саны | |
| Исәпкә алынмаган тәкъдимнәрнед гомуми саны | |